ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 август 2017ел Норлат ав. №26

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус урыннарны билгеләү турында

«Гавами чаралар турында законнарны камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2017 елның 7 июнендәге 107-ФЗ номерлы Федераль законы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба – Башкарма комитет) депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус урыннарны билгеләргә (1 нче кушымта).
2. Депутатлар сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен Норлат авыл җирлеге башкарма комитетындагы биналар исемлеген билгеләргә (2 нче кушымта).
3. Норлат авыл җирлеге башкарма комитетында депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибен расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы., М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Арьягы»үзәге бинасы) халыкка җиткергә.
5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз естемә алам.

Норлат авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Багаутдинов

Норлат авыл җирлеге башкарма
комитетының «21» август, 2017 ел,
№26 карарына 1 нче кушымта

**Норлат авыл җирлеге территориясендә сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннар исемлеге**

1.Норлат авыл җирлеге администрациясе бинасы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46нчы йорт;
2.Норлат урта мәктәбе бинасы, Норлат авылы, Ленин ур., 1нче йорт
3. «Идел Аръягы» мәдәният үзәге бинасы, Норлат авылы, М. Фәйзуллин ур., 17нче йорт
4. «Идел Аръягы»" мәдәният үзәге бинасы, Косяково авылы, Светлая ур., 6нчы йорт.

Норлат авыл җирлеге башкарма
комитетының «21» август, 2017 ел,
№26 карарына 2 нче кушымта

**Норлат авыл җирлеге башкарма комитетында депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар исемлеге**

1. **авыл җирлеге башлыгы кабинеты**
2. **уку кабинеты**
3. **авыл мәдәният йорты фойесы**
4. **авыл мәдәният йорты фойесы**

Норлат авыл җирлеге башкарма
комитетының «21» август, 2017 ел,
№26 карарына 3 нче кушымта

**Норлат авыл җирлеге башкарма комитетында депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибе.**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм Норлат авыл җирлеге башкарма комитетында депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар бирү тәртибен билгели.

2. Норлат авыл җирлеге башкарма комитетында депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен биналар исемлеге әлеге карарның 2 нче кушымтасы белән билгеләнә.

3. Сайлаучылар белән очрашу өчен бүлмәләр биргәндә барлык депутатлар өчен тигез шартлар тәэмин ителә.

4. Биналар эш һәм ял көннәре (бәйрәм) буенча бушлай бирелә.

5. Депутат сайлаучылар белән очрашу бүлмәсе бирү өчен Норлат авыл җирлеге башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) очрашу үткәрелгәнче 2 атнадан да соңга калмыйча бүлмә бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

6. Гаризада чараны үткәрү өчен күздә тотылган дата, аның башы, озынлыгы, якынча катнашучыларның саны, гариза бирү датасы, чараны үткәрү өчен җаваплы затның белешмәләре, элемтә телефоны күрсәтелә.

7. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бинаны бирү турындагы гариза гариза бирелгәннән соң өч көн эчендә Башкарма комитет тарафыннан карала.

8. Әгәр әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән сорала торган бина инде бер депутатка бирелсә, йә мәдәни-массакүләм яисә башка чара уздырганда җәлеп ителсә, Башкарма комитет депутатка шундый ук шартларда бүтән вакытта бина бирүдән баш тартырга хокуклы түгел.

9. Очрашулар уздырганда иминлекне тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**10.** Депутатның җәмәгатьчелек чарасы рәвешендә сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә.